**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены карары**

19 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021 елда Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Татар Буасы авылында юлларны төзекләндерүгә, зиратны төзекләндерү (хуҗалык корылмасын реконструкцияләү һәм инвентарь сатып алу), социаль билгеләнештәге объектларны төзекләндерү, кышкы чорда юлларны карап тоту эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татар Буасы авыл җирлеге башлыгы _________ Р.Ф.Йосыпов

Халык җыены секретаре _________ Р.М.Җамалетдинова